**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 9 апрелендәге 1105 номерлы карары**

**Казан шәһәренең Совет районында ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитутның характеристикасы:

- йогынты ясала торган өлкә мәйданы – 11 067 кв.м;
- үзләренә карата хокуклар чикләнә торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары – 16:16:120601:14698, 16:16:120601:14694;
- урнашу урыны: Казан шәһәре, Совет районы;
- билгеләүнең максаты: җәяү һәм транспортта узуны тәэмин итү;
- билгеләү вакыты: вакыты чикләнмәгән.

1.2. гариза бирүчеләр: Гыйматова Ф.Г., Фәтхуллина Р.Ф., Мортазина Л.Р.;

1.3. билгеләү өчен нигезләр: гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгате, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясы.

2. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталарында каралган чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

3. Әлеге карарның 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.


4. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре Башкарма
комитетының 2025 елның
9 апрелендәге 1105 номерлы
карары белән расланган
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең Совет районында ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре**




| Масштаб: 1:5000<br>Координаталар системасы: МСК-16 | |
|---|---|
| Шартлы билгеләр: | |
| ▭ (кара) | Сервитутлар |
| ⁄ (сызык) | Урамнар (гамәлдәге) |
| ▭ (зәйтүн) | Ясала торган җир кишәрлекләре чикләре (гамәлдәге) |
| ▭ (зәңгәр) | Җир кишәрлекләре |
| ⁄ * | территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар (гамәлдәге) |
| 16:16:120601 | кадастр кварталы |
| 16:16:120601:14698,<br>16:16:120601:14694 | үзенә карата хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |